## КАРАР

**22 ноябрь, 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Югары Шөн авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 22 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге Югары Шөн авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләрдән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Шөн авылының Чапаев, Октябрь, Май урамнарына вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау: проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Шөн авылындагы юлны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында спорт мәйданчыгын төзекләндерү, спорт һәм балалар җиһазлары һәм инвентарь сатып алу һәм урнаштыру: проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында янгын гидрантлары, янгын краны сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылы зиратын төзекләндерү һәм карап тоту, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында су суырту манарасын һәм суүткәргеч челтәрләрне карап тоту һәм ремонтлау, проект-смета документлары.
- Югары Шөн авылында чишмәләрне төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау, проект-смета документлары.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 192 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 99 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 99 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге Югары Шөн авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Шөн авылының Чапаев, Октябрь, Май урамнарына вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау: проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Шөн авылында Октябрь урамыннан Май урамына чыгу юлын ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Шөн авылындагы юлны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Югары Шөн авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу,
- Югары Шөн авылында спорт мәйданчыгын төзекләндерү, спорт һәм балалар җиһазлары һәм инвентарь сатып алу һәм урнаштыру: проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында янгын гидрантлары, янгын краны сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары;
Югары Шөн авылындагы зират коймаларын ремонтлау һәм карап тоту, ритуаль хезмәтләр күрсәтү өчен инвентарь сатып алу, проект-смета документлары;
Югары Шөн авылында су суырту манарасын һәм суүткәргеч челтәрләрне карап тоту һәм ремонтлау, проект-смета документлары.

«РИЗА» «КАРШЫ»
кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Рәислек итүче, Важашур авыл җирлеге башлыгы П.Л. Иванов